КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 15 март г.Казань № 154

Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү тәртибе турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1704 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 15 март, 154 нче
карары белән расланды

Беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә,
айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган
Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен
Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту
кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр «Балалары булган гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 ел, 28 декабрь, ФЗ-418 нче Федераль законның 1 статьясындагы 2 өлеш нигезендә айлык түләүләр алуга хокуклы гражданнарга, беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр (алга таба – субвенцияләр, айлык түләү) тоту тәртибен билгели.

2. Субвенцияләрне тоту бу Кагыйдәләрнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан ирештерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) ай саен, сигезенә кадәр, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына айлык түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә гариза (алга таба – гариза) җибәрә.

4. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – Казначылык) бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм субвенцияләрне финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алганнан соң биш эш көне эчендә Министрлыкка аның гаризалары буенча финаслауның иң чик күләмнәрен ирештерү өчен чыгым расписаниесен Казначылыкка кертә.

5. Субвенцияләрне тоту Министрлык тарафыннан Казначылыкта ачылган шәхси исәпләр аша гамәлгә ашырыла.

6. Министрлык Казначылыктан субвенцияләрне финаслауның иң чик күләмнәрен ирештерү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң биш эш көне эчендә алга таба гражданнарның Россия кредит оешмаларында ачылган шәхси исәпләренә күчерү өчен Казанчылыкка касса чыгымы турында гариза кертә.

7. Министрлыкның тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле булган эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнарын компенсацияләү чыгымнары субвенция хисабыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан айлык түләү рәвешендә түләнелгән акчаның 1,5 проценты чикләрендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

8. Министрлык тарафыннан түбәндәгеләр кертелә:

Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына:

квартал саен, планлаштырыла торган квартал алдыннан килә торган айның 10 ысына кадәр – айлык түләү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә гариза;

ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, – финанслар белән тәэмин итү чыганагы субвенция булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап (алучыларның факттагы санын һәм билгеләнгән һәм гамәлгә ашырылган айлык түләүләр санын күрсәтеп);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына:

ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, – финанслар белән тәэмин итү чыганагы субвенция булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап (алучыларның факттагы санын һәм билгеләнгән һәм гамәлгә ашырылган айлык түләүләр санын күрсәтеп).

9. Бу Кагыйдәләрнең 8 нче пунктында күрсәтелгән гариза һәм хисаплар Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган формалар буенча кертелә.

10. Субвенцияләр җитәрлек күләмдә булмаганда Министрлык, агымдагы финанс елының 15 октябреннән дә соңга калмыйча, бүленми калган резерв акчасын бирү турындагы үтенеч белән Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать итә.

11. Министрлык кертелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субвенцияләрне максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

12. Бирелгән субвенцияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.